ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

31.10.2024___ № 1008______

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» 2019 елның 29 маендагы 773 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә һәм шәһәр һәм авыл җирлекләре бухгалтерларына хезмәт хакы түләү турында» 2024 елның 07 октябрендәге 03-12/7086 номерлы хаты нигезендә һәм муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның «Биектау муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» 2019 елның 29 маендагы 773 номерлы карары (5.10.2020 елның №769, 8.12.2022 елның №1138, 20.06.2024 елның №561карарлары редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Мәдәният бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ Мәгариф бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләре һәм белгечләренең айлык вазыйфа окладлары күләмен 2025 елның 01 гыйнварыннан арттырырга.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУнең Мәдәният бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУнең Мәгариф бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары

һәм оештыру турында» Нигезләмәсенең 3 пунктындагы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре житәкчеләре һәм белгечләре вазыйфаи окладлары» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Җитәкче һәм белгеч вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 37 800 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 36 200 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 36 200 |
| Бүлек башлыгы | 30 500 | 30 500 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 26 800 | 26 800 |
| Бухгалтер | 25 300 | 25 300 |

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хәкимуллин